ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26 12 2023 г. № 1265

«Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны түләүсез ике тапкыр туклануны оештыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 956 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны социаль яклау максатында һәм кулланучылар бәяләре үсешен индексацияләүгә бәйле рәвештә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны түләүсез ике тапкыр туклануны оештыру тәртибен раслау турында» 2022 елның 30 декабрендәге 956 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 2 нче кушымтасын яңа кушымта редакциясендә расларга.

2. «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны түләүсез ике тапкыр туклануны оештыру тәртибен раслау турында» 2022 елның 30 декабрендәге 956 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы А.Х. Гарифуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «26» декабря
1265 номерлы карары белән расланган
Кушымта

## Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәге категориядәге укучыларны тукландыру бәясе

| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1нче - 4 нче сыйныфларда ике тапкыр туклану | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| шәһәр | 119,71 | 52,95 | 26,70 | 40,06 |
| авыл һәм Кама Аланы штп | 119,71 | 52,95 | 26,70 | 40,06 |
| Ике тапкыр туклану. Бер тапкыр туклану - 5-11 нче сыйныфлар | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| шәһәр | 124,30 | 115,10 | 9,20 | - |
| авыл һәм Кама Аланы штп | 105,50 | 96,30 | 9,20 | - |